СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

14.12.2021 № 15/6

На №__________ от______________

# КАРАР

**Тукай муниципаль районы Социаль-икътисадый үсеш фонды идарәсе составына үзгәрешләр кертү турында**

Кадрлар үзгәреше белән бәйле рәвештә, муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Тукай муниципаль районы Социаль-икътисадый үсеш фонды идарәсе составыннан чыгарырга:

Зарипов Галимҗан Сәетҗан улын

2. Тукай муниципаль районы Социаль-икътисадый үсеш фонды идарәсенең яңа составын расларга:

| | |
|---|---|
| Вәзиева Фәйрүзә Фаяз кызы | Тукай муниципаль районы ветераннар (пенсионерлар) җәмгыяте һәм инвалидлар җәмгыяте рәисе; |
| Гыйлаев Файсал Мәхмүт улы | АПК хезмәткәрләре профсоюзының район оешмасы рәисе; |
| Харрасов Җәүдәт Галимҗан улы | Калмия авыл җирлеге Советы депутаты. |

3 Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны бюджет, салымнар һәм икътисадый сәясәт буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе

Ф.М. Камаев

СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

14.12.2022 № 15/7

На № __________ от _______________

# КАРАР

**Тукай муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында нигезләмәне раслау хакында**

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2005 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законны (2021 елның 11 июнендәге 170-ФЗ номерлы Федераль закон редакциясендә) гамәлгә ашыру максатында, муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында нигезләмәне расларга.
2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http:pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Тукай муниципаль районының рәсми сайтында http:tukay.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.
3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе

Ф.М. Камаев

эшчәнлеген гамәлгә ашыручы затлар тарафыннан системада мәгълүмат урнаштыру тәртибенә таләпләр;

10) күпфатирлы йортларда инвалидлар өчен биналарга керү мөмкинлеген тәэмин итүгә таләпләр;

11) социаль файдаланудагы наемга алынган йортларда торак урыннары бирүгә таләпләр.

1.3. Муниципаль торак контроле Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – контроль орган) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

1.4. Башкарма комитетның муниципаль торак контролен гамәлгә ашырырга вәкаләтле вазыйфаи заты булып икътисад бүлегенең әйдәп баручы белгече (алга таба шулай ук – инспектор) тора.

Күрсәтелгән контроль органның вазыйфаи заты вазыйфаи бурычларына аның вазыйфаи инструкциясе нигезендә муниципаль торак контроле буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру керә.

Муниципаль торак контролен гамәлгә ашырырга вәкаләтле вазыйфаи зат муниципаль торак котролен гамәлгә ашырганда, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 248-ФЗ номерлы Федераль закон) һәм башка федераль законнар нигезендә җаваплылыкка ия.

Контроль органының контроль чара үткәрү турында карар кабул итүгә вәкаләтле вазыйфаи затлары булып контроль органы җитәкчесе, җитәкче урынбасары (контроль органның вәкаләтле вазыйфаи затлары) тора.

1.5. Муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру, профилактик чаралар, контроль чаралар оештыру һәм үткәрү белән бәйле мөнәсәбәтләргә карата Россия Федерациясе Торак кодексы, 248-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре кулланыла.

1.6. Муниципаль торак контроле объектлары булып тора:

1) контрольдәге затларның мәҗбүри таләпләр үтәлергә тиешле эшчәнлеге, гамәлләре (гамәл кылмавы), шул исәптән эшчәнлекне гамәлгә ашыручы контрольдәге органнарга әлеге Нигезләмәнең 1.2 пункты 1-11 пунктчаларында күрсәтелгән гамәлләре (гамәл кылмавы);

2) контрольдәге затларның эшчәнлек нәтиҗәләре, шул исәптән әлеге Нигезләмәнең 1.2 пункты 1-11 пунктчаларында күрсәтелгән мәҗбүри таләпләр куела торган продукция (товарлар), эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр;

3) муниципаль торак фондының торак биналары, муниципаль торак фондының торак биналары булган күпфатирлы йортларда гомуми милек һәм әлеге Нигезләмәнең 1.2 пункты 1-11 пунктчаларында күрсәтелгән мәҗбүри таләпләр куела торган башка объектлар.

1.7. Контроль объектларын исәпкә алу түбәндәгеләрне булдыру юлы белән башкарыла:

контроль чараларның бердәм реестры;

судка кадәр шикаять бирү мәгълүмат системасы (дәүләт мәгълүмат системасы подсистемалары);

ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек юлы белән башка дәүләт һәм